ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**01.10.2020**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№1879**

2020 елның 1 сентябреннән Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруга Зеленодольск муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен билгеләү турында

Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, укучыларның балансланган кайнар ризык белән тәэмин итү нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 24 августындагы 728 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» карарына теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү хакында» карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы бюджет ассигнованиеләре күләмен 2020 елның 1 сентябреннән Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруга һәрбер укучыга һәр уку көненә 7 сум 70 тиен күләмендә билгеләргә.

2. Зеленодольск муниципаль районы бюджет ассигнованиеләре күләмен 2020 елның 1 сентябреннән Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруга һәр уку көненә һәр укучыга 58 сум 95 тиен күләмендә түбәндәге категорияләргә билгеләргә:

- үз составында 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдәге укучыларга;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә белем алучы «Норлат балалар йорты» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен;
- Раифа Богородицкий ирләр монастыренең балалар корпусында тәрбияләнүче «Татарстан Республикасы Зеленодольск миуниципаль районының Раифа урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә укучыларына.

3. Уку чорында «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче укучылар өчен, 2020 елга Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр чикләрендә кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы Д. С. Анисимовка Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карар 2020 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин